КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 30 октябрь

г.Казань

№ 1024

«Татарстан Республикасы Милли музее» һәм «Ленино-Кокушкино» дәүләт тарихи-мәдәни музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениеләрен «Татарстан Республикасы Милли музее» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенә «Ленино-Кокушкино» дәүләт тарихи-мәдәни музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесен кушу юлы белән үзгәртеп оештыру турында

Мәдәният тармагы инфраструктурасын оптимальләштерү максатларында һәм Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 57 статьясы, «Коммерциягә карамаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Татарстан Республикасы Милли музее» һәм «Ленино-Кокушкино» дәүләт тарихи-мәдәни музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениеләрен «Татарстан Республикасы Милли музее» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенә «Ленино-Кокушкино» дәүләт тарихи-мәдәни музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесен кушу юлы белән үзгәртеп оештыру турында, үзгәртеп оештырудан соң «Татарстан Республикасы Милли музее» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе эшчәнлегенең төп максатларын һәм исемен саклап калу белән, тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

«Татарстан Республикасы Милли музее» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы гамәлгә ашыра;

«Татарстан Республикасы Милли музее» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан дәүләт биремен үтәүне финанс белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсен үтәүне финанс белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына:

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының «Татарстан Республикасы Милли музее» һәм «Ленино-Кокушкино» дәүләт тарихи-мәдәни музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениеләрен үзгәртеп оештыруны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган нигезендә тәэмин итәргә;

эш көннәрендә исәпләнә торган 60 көн эчендә «Татарстан Республикасы Милли музее» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе Уставына тиешле үзгәрешләр кертергә;

«Татарстан Республикасы милли музее» һәм «Ленино-Кокушкино» дәүләт тарихи-мәдәни музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениеләрен үзгәртеп оештыру нәтиҗәсендә эштән азат ителә торган хезмәткәрләргә гарантияләр һәм компенсацияләр бирүне Россия Федерациясе Хезмәт кодексы нигезендә тәэмин итәргә;

эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә «Ленино-Кокушкино» дәүләт тарих-мәдәни музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе тарафыннан Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына «Татарстан Республикасы Милли музее» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенә беркетү өчен кирәкле документларны, шул исәптән күрсәтелгән учреждениегә оператив идарә итү хокукында беркетелгән дәүләт мөлкәтен, шул исәптән күчемсез милек объектларына техник документацияне бирүне тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына “Татарстан Республикасы Милли музее” Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе Уставына кертелгән үзгәрешләрне дәүләт теркәвенә алганнан соң:

эш көннәрендә исәпләнә торган 60 көн эчендә оператив идарәсе хокукында элек «Ленино-Кокушкино» дәүләт тарихи-мәдәни музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенә оператив идарә хокукында беркетелгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен «Татарстан Республикасы Милли музее» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенә беркетергә;

эш көннәрендә исәпләнә торган 90 көн эчендә җир кишәрлекләреннән даими

(вакыты чикләнмәгән) файдалану хокукында «Татарстан Республикасы милли музее» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенә аларда элегрәк «Ленино-Кокушкино» дәүләт тарихи-мәдәни музей-тыюлыгы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесенә беркетелгән күчемсез милек объектлары урнашкан җир кишәрлекләрен бирүне тәэмин итәргә.

5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасы икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә әлеге карарның 3 һәм 4 пунктларында күрсәтелгән чаралар тәмамланганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән 60 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасының тиешле норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр әзерләргә һәм тапшырырга.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин